Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№22 (35)

6 сентябрь 2012 ел

## • Ике авыз сүз

23 август көнне Казан университетына **КФУНЫҢ КАЙГЫРТУЧАНЛЫК СОВЕТЫ РӘИСЕ – ТРНЫҢ ПРЕЗИДЕНТЫ РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ КИЛДЕ.** Ил башлыгы университетның төзелеш эшләре бара торган мөһим объектлары: Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының лаборатория корпусын, ашханәне, А.М.Бутлеров ис. Химия институтының фәнни һәм лаборатория биналарын, ИТИС югары мәктәбен, шулай ук UNIVER матбугат үзәге белән танышты.

• • • •

28 август көнне Казан федераль университетында **ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ.** Беренче булып икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы Үсеш программасының барышы белән таныштырды. Хуҗалык эшләре буенча проректор Ленар Сафиуллин КФУда бара торган төзелеш һәм ремонт хакында иkenче булып чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, төп биналарда төзекләндерү эшләре 10-15 сентябрьгә тәмамланачак. 2012 елгы кабул итү кампаниясе нәтиҗәләре белән КФУның кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе Сергей Ионенко таныштырды. Соңыннан мәгълүматлаштыру һәм элемтә Департаменты эшчәнлеге турында хисап каралды. Департамент директоры Дмитрий Бурмистров соңгы елда гамәлгә ашырылган зур проектлар турында сөйләде.

• • • •

31 август көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ** Универсиада дирекциясе җитәкчесе урынбасары **А.КАДЫРОВ** белән **«АТЭС-2012 ҺӘМ УНИВЕРСИАДА: ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЫ ЗУР МАСШТАБЛЫ ЧАРАЛАР МӘЙДАНЫ»** исемле видеоконференциядә катнашты. «Просвещение» каналы оештырган телекүпер КФУ, Ерак көнчыгыш ФУ һәм Мәскәүнең «МИСиС» Милли тикшеренү технология университеты вәкилләрен берләштерде.

• • • •

1 сентябрь көнне **КФУ БАЗАСЫНДА СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН IT-ЛИЦЕЙ АЧЫЛДЫ.** Чарада катнашкан ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җиһазлар өчен 45 млн. 482 мең күләмендә сертификат бүләк итте. Лицейның төп максаты: балаларның индивидуаль сәләтләрен, иҗади башлангычларын үстерү, заманча мәгълүмати технологияләрне үзләштерү. Яңа ачылган лицейга сәләтле балаларны Татарстан төбәкләреннән генә түгел, Идел буе округы һәм Россиянең башка төбәкләреннән дә кабул итәчәкләр.

• • • •

1 сентябрь көнне Россиянең иң заманча студентлар шәһәрчеге территориясендә **УНИВЕРСИАДА АВЫЛЫНЫҢ МЕДИЦИНА ҮЗӘГЕ АЧЫЛДЫ.** Үзәктә туды-рылган шартлар дөрес диагноз куярга, пациентлар өчен сыйфатлы дәвалау үткәрергә ярдәм итәчәк. Поликлиникада бөтен Казан университетларында көндезге бүлектә укучы барлык студентларга беренче медицина ярдәме күрсәтеләчәк. Үзәктәге даруханәдә дарулар бушлай биреләчәк. Табибка электрон чират аша язылып була, моның өчен регистратура ике инфомат белән җиһазландырылган.

• • • •

КФУның теоретик физика кафедрасы профессоры **Р.НИГЪМӘТУЛЛИН Г.М.ЗАСЛАВСКИЙ ПРЕМИЯСЕНӘ ЛАЕК БУЛДЫ.** Галим физика фәне үсешенә шактый өлеш кертә. Ул Г.Прони мәсьәләренең яңа чишелешен, вакланмалы интегралның фи-зик мәгънәсен уйлап таба, диэлектрик релаксация теориясен үстерә.

• • • •

8 сентябрь көнне сәгать 10:00да **«МӘСКӘҮ» СПОРТКОМПЛЕКСЫ АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ УЗДЫРА.** Чарада секцияләр белән таныштыру һәм аларга язылу булачак.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Рөстәм Кадыйров фотосы

# Океан артында кунакта

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

ТР президенты Рөстәм Миңнеханов 3 сентябрьдә Питтсбургка (АКШ, Пенсильвания штаты) эшлекле сәфәргә китте. Делегация составында Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров, ТРның мәгълуматлаштыру һәм элемтә үзәге вице-премьеры Роман Шәйхетдинов та бар.

Очрашуның максаты: ТР вәкилләренең Карнеги Меллон университеты (Carnegie Mellon University) эшчәнлеге белән танышу. Әлеге уку йорты компьютер технологияләре буенча белгечләр әзерләүдә «Дөньяның иң яхшы вузлары» рейтингында алдагы урыннарда тора. Карнеги-Меллон университетына 1967 елда нигез салына. Уку йорты фән һәм техника өлкәсендә эзләнүләр алып бара, менеджмент, икътисад, лингвистика өлкәсендәге уңышлары белән башка төбәкләргә дә билгеле.

Белүебезчә, алга таба республикабызда барлык уңайлыклары белән Иннополис дигән инновацион шәһәрчек төзергә планлаштыралар. Анда укучы һәм эшләүче 60 мең «айтишник» гаиләләре белән яши алачак.

Иннополис территориясендә IT-университет ачылачак. Ә белем бирү программасын Carnegie Mellon(АКШ) университеты белән берлектә эшләргә уйлыйлар. Шул уңайдан АКШтагы очрашуларның күпчелеге нәкъ менә Карнеги Меллон университеты җитәкчелеге белән планлаштырылган.

Татарстан делегациясе шулай ук iCarnegie штаб-фатирында, Карнеги Меллонның архитектура факультетында һәм башка фәнни үзәкләрендә дә булды.

Тагын шунысын билгеләп үтәргә кирәк, Казан университеты инде шактый вакыт АКШның фәнни университетлары белән элемтәдә тора. Питтсбург дәүләт университеты, Нью-Йорк штаты университеты, Аризона штаты университеты, Төньяк Каролина штаты һәм Индиана штаты университетлары. Моннан тыш, бик күп еллар рәттән Казан университеты америка профессорларын үзендә кабул итә, Фулбрайт программасы стипендиатлары студентларга үзләренең лекцияләрен укый.

*Матбугат үзәге мәгълүматлары файдаланылды.*

## • Белем көне

# Хәерле сәгатьтә!

**Алинә Садыйкова,**
хәбәрче

Яңа уку елы башлану уңаеннан беренче сентябрь көнне Спорт Сараенда тантаналы чара булып узды

Әле кичә генә кайсыларын җәйге ялга, кайсыларының кулларына диплом тоттырып олы юлга озаткан университетыбыз янәдән студентларын каршы алды. 8000нән артык кечерә мәктәп укучысы уку йортыбызның бусагасын атлап керде.

Белүебезчә, Белем бәйрәме беренче сентябрь көнне уздырыла. Бу бәйрәм 1984нче елда СССРның Югары Советы тарафыннан рәсми рәвештә кабул ителгән.

**Ахыры 2нче биттә.**



Әмир Фазлыйәхмәтов фотосы

• Фән дөньясында

# Галәм үзәге - Казанда

**Алинә САДЫЙКОВА, Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрчеләр

3 сентябрь көнне КФУның Актлар залында «Рентгенлы күк: йолдызлар һәм «кара тишемнәр»дән алып космологиягә кадәр» исемле Халыкара конференциясе башланып китте.



Алия Галимуллина фотосы

Конференциянең оештыручылары булып, ТР Фәннәр академиясе, КФУның астрономия һәм космик геодезия кафедрасы, Россия Фәннәр Академиясенең космик тикшеренүләр институты (Мәскәү), Макс Планк исемендәге астрофизика институты (Германия) тора. Оештырылу урыны итеп Казан шәһәре юкка гына сайланмаган. Казан астрофизиклары алдагы космик экспериментларда да актив катнашып, уңышлы нәтиҗәләргә ирешкән.

Россиянең эре шәһәрләреннән, АКШ, Германия һәм башка чит илләрдән килгән атаклы астрофизиклар 2014 елда Җир янындагы орбитага «Спектр-Рентген-Гамма» космик обсерваториясен очыруга бәйле фәнни һәм техник проблемаларны тикшерәчәк. «Спектр-Рентген-Гамма» галәмдәге уникаль объектлар: төрле күләмдәге «кара тишемнәр», актив галактикаларны өйрәнә торган спутник. Чараны КФУның Президенты Мәгъсүм Сәлахов ачып җибәрде. Ул конференция темасының университет өчен бик әһәмиятле булуына басым ясады. Уку йорты оешканнан бирле (1804 ел) аның фәнни тематикасында астрономик юнәлеш һәрдаим сакланып килде.

КФУның астрономия һәм космик геодезия кафедрасы мөдире Наил Сәхибуллин, ТР Президенты исеменнән ТР Фәннәр академиясе Президенты Әхмәт Җәүһәров, Мәскәү астрономнары исеменнән Дәүләт астрономия институты директоры, академик Анатолий Черепащук конференциядә катнашучыларны сәламләде.

Кереш докладлар белән беррәттән фәнни секцияләр, пленар утырышлар уздырыла. Галимнәрнең конференцияләре 7 сентябрьдә төгәлләнәчәк. Конференция инглиз телендә бара. Тезисларны бастыру планлаштырылмый, әмма чыгышларны конференция сайтында табарга мөмкин булачак.

• Белем баскычлары

# ТИНне мөгаллимнәр үзләре дә укый

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче



Казан федераль университетының Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү үзәгендә «Тормыш иминлеге нигезләре» белгечлеген алмаган укытучылар өчен махсус-һөнәри белем бирү курсларының дүртенче сессиясе тәмамланып килә. Монда республикабызның төрле районнарыннан килгән 26 укытучы белем ала.

Курсның җитәкчесе – педагогика фәннәре кандидаты ИБӘТУЛЛИН Альберт Габделхәлим улына балаларның иминлеген саклау, аларны өйрәтү рәвешен аңлатып үтүен сорадык. Альберт әфәнде сүзен: «Мәктәптә ТИНне өйрәнү – укучыларны тормышка әзерләү ул», - дип башлады. «Бүгенге көндә илдә балаларга каршы күп җинаятьләр кылына. Җинаятьчеләр корбаны булмас өчен, ТИН дәресләрендә укытучы балалар белән индивидуаль рәвештә саклык кагыйдәләрен үтәүне, андый очракларда үзләрен ничек тотарга икәнен өйрәтергә тиеш. Укытучы һәр укучының кайда яшәве белән кызыксынырга, аларга мәктәптән кайтканда, кичке якта урамда, җәмәгать урыннарында йөргәндә куркынычсызлык кагыйдәләре турында һәрдаим искәртеп торса әйбәт булыр иде. Кайбер балалар чит кешеләр белән аралашырга ярата, үзләре дә белмичә бөтен уй-фикерләрен чит кешегә әйтеп сала. Нәтиҗәсе бик аяныч: алар җинаятьченең тозагына эләгә. Хәзер күпчелек гаилә өлкәннәрдән аерым яши бит. Ата-ана көне буена эштә, балага еш кына өйдә берьялгызы калырга туры килә. Бу очракта аның иминлеген ничек тәэмин итәргә соң?

Бала укытучының ТИН дәресләрендә аңлаткан бик гади генә берничә кагыйдәне искә төшерергә тиеш: таныш булмаган кеше ишек шакыганда, шәһәр җирендә яшәгән бала махсус тишектән карарга, әгәр белмәгән кеше булса, бөтенләй ишекне ачмаска тиеш. Әгәр таныш түгел кеше һаман тора бирсә, күршеләргә яки полициягә шалтыратырга кирәк. Телефон кинәт эшләүдән туктаса, ә ишекне ачарга маташа башласалар, идәнгә, диварга, җылыту батареяларына сугып күршеләрне ярдәмгә чакыру мәслихәт. Тәрәзәне ачып яки балконга чыгып та ярдәмгә кешеләр чакырырга мөмкин. Мәктәптән кайткач, бала ишекнең ярымачык торганын яки йозакның ватылуын һәм өйдә чит кешеләр барлыгын күрсә яки ишетсә, фатирга кермәсен. Мондый очракта шыпырт кына күршеләргә кереп полициягә шалтыратсын.

Баланы телефоннан да алдарга мөмкиннәр. Шуңа күрә, таныш булмаган кешеләр белән сөйләшергә, өйдә үзе генә калуын яки әти-әнисенең исемен әйтергә ярамый. Әгәр кем дә булса: «Мин синең әти-әниең белен таныш, әйбер калдыру өчен өегезгә керергә телим, — дип әйтсә, моны кичекмәстән әти-әнисенә шалтыратып әйтү мотлак. Кайбер ата-аналар күршеләре белән кыен минутларда балаларына ярдәм итешү турында килешеп куя. Бик дөрес эшли дә! Нәтиҗәдә бала үзен һәрчак яклаучы барлыгын тоя, кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген дә белеп тора.

Ни кызганыч, балаларга һөҗүм итүче җинаятьчеләр тышкы кыяфәтләре, үз-үзләрен тотышлары буенча башка кешеләрдән аерылып тормый. Мәсәлән, фаш ителгән женси маньякларның барысының да игътибарлы, кеше хәленә керүчән, ачык йөзле булуы ачыкланган. Аларның кайберләре укытучы булып эшләгән, балалар белән аралашу күнекмәләрен үзләштергән. Бала мәктәп яшендә икән, атаана бала белән бергәләп ТИН дәресләрендә алган белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту сорала. Чөнки укытучы мәктәптә балаларның иминлеге турындагы мәгълүматны бик яхшылап төшендерергә омтыла, Һәр бала белән аерым эшли. Ә тормышта, өйдә бу күнекмәләрне әти-әниләр дә ныгытырга, гел искәртеп торырга бурычлы. Баланың холкына, ихтыяр көченә, кыюлыгына, үзен-үзе яклый белүенә дә күп нәрсә бәйле. Ә бу сыйфатлар нәкъ менә иң беренче – гаиләдә, аннары мәктәптә – ТИН дәресләрендә бик җентекләп, һәр балага индивидуаль якын килеп үзләштерелә».

«Сакланганны сакләрмын» дигән гыйбәрә бик дөрес. Шул канатлы сүз беребезнең дә исеннән чыкмасын иде.

• Мөхәррир сүзе

**Рифат СӘЛАХ**



## *Хөрмәтле укучыларыбыз!*

*Сез шундый бәхетле дөньяда яшисез! Һәр иртә белән торып укырга барасыз, һәр көнегез яңадан-яңа кичерешләргә бай. Сезнең яныгызда чынлап та рәхәт! Моннан берничә ел элек кенә сез йөргән юлларны таптап, сез утырган аудиторияләрдә нәкъ сезнең кебек лекция тыңлап, сирәк кенә йоклап та алган бер студент идем. Үткәннәргә кайтып булмый дисәләр дә, янәдән сезнең янығызга кайтып, бәхетле мизгелләрне кабат яңартырга насыйп булды.*

*Табигатьнең укуга тәэсире дә көчле шул! Көзнең беренче аенда студентларның укуда гаме булмый. Шундый матур көннәрдә дәресләрне тозлап, «тәрәзә»ләрдә урамга чыгып рәхәтләнеп йөрисе килә бит. Азмы-күпме яңгырлар башлангач кына китап-дәфтәрләрне актара-актара дәресләргә әзерләнәсең: язасың-сызасың, ксерокстан чыгарган язуларны дәфтәргә ябыштырасың...*

*Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алырга кушылган бер хәдистә. Белгечләр әйтүенчә, гыйлемле, интеллектуаль яктан югары булган кеше җәмгыятькә зыян китерә торган гамәлләрне, җинаятьләрне бик сирәк эшли икән. Университетта уку — белгечлек буенча белем алу гына түгел, тормыш гыйлемен дә тупларга ярдәм итә, кешегә әхлаклы булып тәрбияләнергә дә мөмкинлек бирә.*

*Сезне дә бу уку елында яңадан-яңа укытучылар, яңадан-яңа фәннәр көтәдер. Безнең «Дарелфөнүн» - Фәннәр патшалыгында да үзгәрешләр. Газетабызга да яңа сулыш керер, яңа рубрикалар барлыкка килер, Алла бирсә. Казан университетының һәр студенты үзенең уй-теләкләрен җиткерә, газетабызны чыгаруда үз өлешен кертә ала. Сездән кызыклы хатлар, яңа фикерләр көтәбез.*

*Баллы-рейтинглы системада умарта кортларыдай күбрәк «бал» җыярга, яңадан-яңа уку елында яңадан-яңа уңышлар телим сезгә! «Дарелфөнүн» белән дә танышып барырга онытмагыз!*

• Белем көне

# Хәерле сәгатьтә!

**Башы 1нче биттә.**

Университет, гадәттәгечә, яңа дусларын бәйрәмгә әзерләп көтеп торды. Тантананы ТРның халык артисты, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының режиссеры Эдуард Трескин башлап җибәрде. Ул барлык студентлар гимны булып саналган «Gaudeamus»ны башкарды. Бәйрәмнең рәсми өлешендә инде университетны тәмамлаган, «кичәге» студентлар үзләренә алмашка килгән яңа буынны каршылап, аларга киңәшләрен биреп калырга ашыктылар. Беренче курслар, үз чиратында, бар көчләрен биреп укырга һәм университет исеменә тап төшермәскә сүз бирде.

Чарада Казан шәһәренең мэры Илсур Метшин, КФУ ректоры Илшат Гафуров, ТРның мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов катнашты. Ректорыбыз студентларның язмышларын КФУ белән бәйләвен хуплады һәм рәхмәт сүзләре белдерде. «Алга таба сез университетыбызның горурлыгы булырсыз», – дип өмет баглады. Казан мэры Илсур Метшин студентларны тәбрикләде, профессорлар һәм педагогларга хезмәтләре өчен зур рәхмәтен җиткерде.

Казан университетының бию коллективлары килгән кунакларның күңелен ачты. Программада татар биюләре, универсиадага багышланган номерлар бар иде. Алар һәр кешенең күңелендә якты тәэсирләр генә өләште. Бөтен дөньяга танылып өлгергән битбоксер Митя Бурмистров беренче курс студентларына ничек укырга, нинди максатларга омтылырга кирәклеген, шул ук вакытта студент тормышының иҗади ягы турында да онытмаска кирәклеге турында сөйләде. Рус эстрадасының Hi-Fi музыкаль коллективы җырларын бүләк итеп, тамашачыларның күңелләрен тагын да күтәрде.

Шушы ук көнне беренче курслар кулларына студент билетларын алды. Кайберләре үзләренең университеттагы беренче уку көне турында тәэсирләре белән дә уртаклашты.

***Алинә Галимова, Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты:*** «Беренче тойгылар зарланырлык түгел. Тик шулай да тау кадәр өеп конспектлар бирделәр, өйрәнеп кенә бетер. Укытучылар әлегә кырыс түгел, шаярып сөйләшәләр, беренче көннән үк куркытмыйк инде диләр бугай... Гомумән, мин бу уку йортына керүемә сөенеп туя алмыйм. Ә алдагысын вакыт күрсәтер...».

***Рәзилә Гыйләҗиева, Филология һәм сәнгать институты:*** «Беренче көн уку йортында... таныш булмаган йөзләр, чит диварлар, күңелгә ят булган сәер мохит – кыскасы, башымда бөтенләй миңа хас булмаган хисләр кайнаша. Шулай саташып йөргәндә, үземнең төркемне чакырганнарын ишеттем. Ниһаять, мин безнекеләр «тәлинкәсендә». Аудиториягә кереп утыру белән, читтән генә булачак төркемдәшләремне күзәтәм: кемнәрдер инде танышып та өлгергән, рәхәтләнеп бер-берсе хакында «белешмә» алып утыралар, ә кемнәрдер ишеккә төбәлеп, нindирәк укытучы керер икән дип көтәләр. Әйе, шулай итеп минем дә мәктәп елларымның бите ябылып, яңа студент тормышы башланып китте...».

***Зөһрә Фәсхиева, Икътисад һәм финанс институты:*** «Беренче уку көне, әлбәттә, бик дулкынландыргыч булды. Һәрнәрсә яңа: төркемдәшләр, уку йорты, укытучылар...Бер мизгелгә хәтта куркыныч та булып китте: шушы шәһәр шаукымына ияреп китә алырмынмы, сынауларга бирешмәмме һәм башка шундый йөз төрле сорау башта... Хәер, уку энә белән кое казу диләр, армый-талмый укырга язсын инде безгә!»

Шулай итеп, яхшы һәм күтәренке кәеф белән яңа уку елына аяк бастык. Хәерле сәгатьтә!

• Безнең юбиляр

# Алтмыш ул - егетләр яше!

**Рөстәм ФӘРХУЛЛИН,**
Экология һәм география институты ассистенты

Кайбер кешеләрнең эшчәнлегенә сокланмый һич мөмкин түгел. Педагогика фәннәре докторы, профессор, РФнең мактаулы хезмәткәре, ТРның атказанган укытучысы, КФУның экология һәм география институтында география һәм экологик белем бирү бүлеге мөдире ГАЙСИН Илгизәр Тимергали улының хезмәте дә әнә шундыйлардан. Әле күптән түгел генә университетыбыз галиме үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтте.

Эш сөючәнлеге, максатчанлыгы, көчле характеры һәм үз профессиясенә тугры булуы аңа хезмәттәшләре, укытучылар һәм студентлар арасында тиз арада абруй яуларга ярдәм иткәндер, мөгаен.

Илгизәр Тимергали улы 1952 нче елның 15 нче июлендә Тукай районы Казаклар авылында эшчеләр гаиләсендә дөньяга килә. 1960-1973 нче елларда Теләнче-Тамак урта мәктәбендә белем ала. Бер ел эшләп алганнан соң, 1971-1973 нче еллар арасында Ватан алдындагы изге бурычын үти- Мәскәү янында хәрби хезмәттә була. Инде армия сафларыннан исән-сау әйләнеп кайткач Сарман районы Петровск урта мәктәбенә укытучы булып китә. Озак та үтми ул 1974 нче елда КДПУның табигый география факультетына көндезге бүлеккә укырга керә. 5 елдан соң инде тәмам җитешкән география һәм биология белгече булып университетны тәмамлый.

Илгизәр абый яшьтән үк үзендәге укытучылык сәләтләрен күрсәтә башлый. Һәрвакыт үзенең активлыгы, оештыру эшләрендә һардаим булышып торуы белән аерылып тора. Әлбәттә, бүгенге мактаулы исемнәренә ирешкәнче аңа бик күп баскычлар үтәргә туры килә. Укытучы, директор, тәрбия эшләре буенча урынбасар, проректор, депутат, кафедра мөдире... Саный китсәң аның башкарган вазифалары бихисап!



Профессор Илгизәр Тимергали улы җитәкчелегендә барлыгы 25 аспирант педагогия фәннәре кандидаты исемен алу өчен диссертация яклый. Бүгенге көндә аның кул астында төрле дәрәҗә алган укучылары үзләренең эшчәнлеген КФУ, КДТУ, КДЭУ, Мари дәүләт университеты кебек билгеле уку йортларында хезмәт куя. Галимне Россиянең бик күп регионнарында белүләре бер дә сәер түгел. Ул күпкырлы хезмәтләре, педагогика өлкәсендә яулаган уңышлары өчен Ушинский, Вернадский исемендәге медальләргә лаек булган шәхес.

Ә без исә, үз чиратыбызда Гайсин Илгизәр Тимергали улына алдагы көннәренең дә кызыклы вакыйгаларга бай булуын, тормыш каретасының акрын гына сикәлтәләргә бирешмичә тәгәрәвен, күпсанлы хезмәтләренең киләсе буыннар тарафыннан югалмыйча кулланылуын теләп калабыз. Юбилеегыз белән Сезне!

*Зилә ФӘСХИЕВА әзерләде*

• Очрашулар



# Төрек һәм татар галимәсе

**Лилия ЯКУПОВА,**
Филология һәм сәнгать институты студенты

*«...Дөньяда бер генә нәрсә дә очраксыз түгел. Һәр хәл, һәр мизгел аерым бер мәгънәгә ия...»*

Шундый сүзләр белән башлады үз чыгышын университетыбыз кунагы Чулпан Зарипова. Чынлап та, аның тормышына карап, бу сүзләр белән килешми мөмкин түгел. Кечкенәдән Төркия әдәбиятына, мәдәниятенә сокланып үскән кызчык, төрек телен өйрәнә. Казан дәүләт педагогика университетында галим буларак карьерасын башлый. Озак та үтми, тырыш, сәләтле яшь җилкенчәк, Төркиягә баргданда теләк теләп суга ташлаган тәңкә тәэсире беләнме, төрек егетенә гашыйк булып, аңа кияүгә чыга. Чит җиргә кияүгә китү бер, ә менә алган белемнәреңнең әҗерен күрерлек, алардан файдаланырлык эш урыны таба алу икеле. Арча якларында туып үскән төрек җанлы татар кызы анда да югалып калмый. Ул ун ел Төркиянең Мугъла шәһәрендә Мугъла университетында «Чордаш төрки телләр һәм әдәбиятлар» кафедрасында укыта, бүгенге көндә Карс шәһәрендә Кавказ университеты «Славян телләре һәм әдәбиятлары» кафедрасында галимәлек һәм укытучылык эшен дәвам итә. Галим булу өстенә тәрҗемә эше белән дә уңышлы шөгыльләнеп килә. Татар әдипләренең шигъри һәм чәчмә әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итә. Г.Тукай, Х.Туфан, Р.Миңнуллин, Р.Гаташ, Г.Исхакый әсәрләрен Чулпан ханым төрки кардәшләребез теленә күчергән.

Чулпан Зарипова кечкенәдән үзе дә иҗат эше белән шөгыльләнә. Беренче шигырьләре «Мәгърифәт» газетасында, үсә төшкәч, «Казан утлары», «Идел», «Мәйдан», «Сөембикә» журналларында басылып тора. Бүгенге көндә Чулпан Зарипова берничә шигъри җыентык иясе. Аның шигырьләрендә Төркия диңгезләренең шаян-шук тавышын да, биек кыяларының моңсу салкынлыгын да тоярга мөмкин. Иҗат җимешләренең чагыштыруларга бай булуы зур тәэсиргә ия.

Сөйли китсәң, Чулпан апа, аның эшчәнлеге, шигърияте турында туктамый сөйләргә мөмкин булыр иде. Аның белән аралаша башлауга зыялылыгына хәйран каласың! Очрашуыбыз да шуңа күрә бик күңелле, сорауларга бай булды.

Чулпан Зарипова-Четин галим, тәрҗемәче, шагыйрә булуы өстенә гаилә учагын саклаучы үрнәк әни дә хатынкыз да. Аңа киләчәктә дә эшчәнлегенең уңышлы дәвам итүен, гаиләсендә хөрмәт, мәхәббәт хөкем сөрүен теләп калабыз.

Шулай ук һәрдаим әлегедәй кызыклы һәм тәрбияви очрашулар үткәреп торучы Ләйлә апа Ихсановнага да рәхмәтебезне җиткерәсебез килә. Алга таба да бергә-бергә эшләргә язсын!

• Җәйге ял

**Илфат ВӘЛИЕВ**
Идарә итү һәм территориаль үсеш институты





Сәләт... Җөмһүриятебездә яшәүче һәр кеше бу сүзне ишеткәндер. Әмма анда барып кайтканнар бу кәлимәнең мәгънәсен унбиш меңләп егет-кызны җыйган оешма гына итеп түгел, тугры дуслар, гомер буена онытылмаслык кичләр, сагындырырлык аланнар итеп күз алдына китерә.

# Бер тапкыр килеп күрүең яхшырак!

Үземнең кыска гына 17 еллык гомер эчендә күп җәйге лагерьларда булырга туры килде, ләкин «Сәләт» аланы ул бөтенләй башка. Моның сәбәпләре бик күп.

Беренчедән, әйдаманнары менә дигән! Дөресен генә әйткәндә, теләсә кем килеп эшләп йөри алмый монда. Аның өчен әйдаманнар мәктәбе дигән иләк аша үтеп, күп конкурсларда катнашып чыныгырга кирәк. Үзләре дә, гамәлләре дә балаларга үрнәк булырга тиешбит аларның! Һәр төркемгә бирелгән абый белән апа кыска гына вакыт эчендә балалар өчен эти белән әнигә әйләнә. Ул гына да түгел, алар сердәш тә, яхшы дус та.

Икенчедән, аланнарга килүче балалар – сәлкешләр. «Сәлкеш» сүзе «сәләтле кеше» дигәнне аңлата. Сәлкеш булыр өчен балалар конкурс яки республика олимпиадалары аша үтә. Чынлап та, үзең кебек үк сәләтле балалар белән 18 көнлек кыска гына ял да онытылмаслык булып һәрберебезнең дә күңел түрендә кала.

Өченчедән, анда үткәрелгән һәр чара, һәр кичә искиткеч! Алар интеллектуаллар өчен дә, шаярырга яратучылар өчен дә, спортсменнар өчен дә файдалы да, истә дә калырлык. Монда борын-борыннан килгән татар мәдәнияте, яшьләрне кызыксындырган өрңяна юнәлешләр белән бергә кушыла, олыларның киңәшләренә балалар колак сала. Әлбәттә, бу сәләтле балалар барысы да үзен киләчәктә республикабызның дәрәҗәсен күтәрү өчен дә күп гамәлләр эшләр. Монда һәркем үзендә яңа сәләт ача: җырламаганы сайрый башлый, биемәгәне сәхнәдә мәтәлчек кенә атмый инде! Монда йокы дигән нәрсә генә юк. Сәлкешләр иртәдән кичкә кадәр бер дә тик тормый. Төрле чаралар оештыралар, кызыклы уеннар уйлап табалар, гыйлем туплый, төннәрен бүлмәләрдә караватта яткан килеш тә бергәләп иҗат итә.

Дүртенчедән, һәр сәлкешнең өзелеп яраткан Биләр фестивале бар. Бөтен аланнар Биләрдә җыелып ярышларда катнаша, иң яхшы ШТК мәзәкләре, иң көчле спортчылар, иң оста биючеләр, җырчылар монда сәләтләрен күрсәтә. Иң шәп аланны да монда сайлыйлар. Биләрдәге җыенда президентыбыз Рөстәм абый Миннеханов та даими кунак.

Сәләтлеләрнең дус булулары гаҗәпләндерә мине. Бергә очрашырга сәбәп табып кына торалар. Җәйге аланнардан башка Бикмуллин фестивале, Әйдаманнар мәктәбе, Алтын каләм бәйгесе, Язгы һәм Көзге сессияләр, гадәткә кергән җәй ахырында университет янында очрашулар... Күңелсез яшәми бу яшьләр! Ләкин күпме генә язма, күпме сөйләмә, барыбер «Сәләт» тойгыларын аңлатып бетереп булмас. Ун тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр килеп күрүең яхшырак. Рәхим итегез, дуслар!

## Илһам канатында



**Фарсыева Гүзәл Зәет кызы** 1994 елның 9 мартында Актаныш авылында туа. Бүгенге көндә Филология һәм сәнгать институтының тәржемә һәм мәдәниятара бәйләнешләр бүлегенең I курсында белем ала. Журналистика, психология фәннәре белән кызыксына. Матур әдәбият укырга, фәнни тикшеренүләр үткәрергә ярата. Мәктәп елларында ук иҗат белән шөгыльләнә башлый, бик күп хикәяләр һәм повестьлар авторы. IV Бөтенроссия «Илһамлы каләм – 2012» әдәби әсәрләр конкурсының гран-при иясе. Бүген без сезгә Гүзәл иҗатының бер өлешен тәкъдим итәбез.

# Укытучым – юлымда син якты маяк

***(Нәсер)***

***Укытучым!***

Син тәүге кат мәктәп ишеге төбендә мине зарыгып көтеп алдың, назлы яз җиледәй иркә карашың белән күңелемнең иң нечкә хисләрен уяттың һәм ягымлы тавышың белән үз артыңнан әйдәдең. Минем өчен бөтенләй чит-ят бинага алып кереп, аның аерылгысыз бер кисәге иттең.

***Укытучым!***

Серледән-серле, могҗизалы белем ишекләрен киң итеп ачып, карашың белән мине очсыз-кырыйсыз гыйлем диңгезенә салдың. Юк, һич тә батырмадың, ә бәлки тирән гыйлем диңгезендә армый-талмый, иң мөһиме колач салып йөзәргә өйрәттең. Ә үзең мине һәрдаим күзәтеп тордың, бер мизгелгә дә күз уңыннан җибәрмичә якты ышаныч һәм таяныч маягы булып нур чәчтең. Шул изге, сихри нурларыңның һәммәсе күңелемдә раушан көзгедәй төгәл чагылыш тапты. Әйе, син мине сансыз йомычка итеп дулкын кочагына рәхимсез рәвештә ташламадың, диңгез чоңгылына качкан барлык асылташлардан, кыйммәтле энҗе бөртекләреннән күпкә әһәмиятлерәк, диңгезнең яшерен шарлавыгыннан да куәтлерәк, бәһале, төпле һәм алыштыргысыз белем бирдең.

***Укытучым!***

Син мине җиңел кәсепкә дә, ансатлыкка да өйрәтмәдең. Син агым уңаена салынып кына барырга түгел, ә дулкыннарга бирешмичә йөзгә-йөз, кара-каршы аяусыз көрәшергә өйрәттең. Үзең әүвәл үрнәк күрсәтеп, мине кайгылардан, бәла-казалардан качмаска, аларны, киресенчә, бил алышып җиңәргә өйрәттең. Тормышның тигезлекләрдән генә тормавына да мин синең аша төшендем.

***Укытучым!***

Син мине тын диңгез көенә генә тибрәтмәдең, шаулы һәм берсеннән-берсе дәһшәтлерәк язмыш дулкыннары белән кыйнап сынадың. Шулай итеп, миндә яшәүгә мәхәббәт, һәр туар таңга яңа омтылыш һәм теләк уяттың. Якты җиһанда яшәүнең дә бәхет икәнен синең канат астында аңладым.

***Укытучым!***

Син миңа һәрбер җан иясенең яшәргә тулысынча хаклы икәнен төшендердең. Ходай җан кызганмаган бәндәнең юлына аркылы каен булып аумаска, яшәргә дип туган инсан яшәсен һәм үз артыннан үкенерлек эшләр калдырмыйча, үтәр юлын гөлчәчәктәй гүзәл гамәлләр белән бизәсен дидең.

***Укытучым!***

Тора-бара диңгез ташыдай мин дә шомардым, мөстәкыйльгә әверелдем. Ә беләсеңме, мин бит бу офык белән шәфәкъне тоташтыручы диңгезнең бер нәни тамчысы гына булганмын! Әмма дә ләкин, тамчы тамып таш ярасына шикләнмичә,син иңнәремә ышанычлы, ныклы канатлар куйдың, куеныңнан аерылып, тәүге кат ярдан-ярга бәргәләнеп очарга өйрәнгән акчарлагыңны син моңаеп,яшь аралаш изге фатихаң белән озатып калдың.

***Укытучым!***

Син сукмак ярган юлдан тайпылмадым. Авыр булсын, читен һәм тынгысыз, хәтта соңгысы булсын, әмма алга, бары тик алга атлаудан ары әмәл тапмадым. Күрәсеңдер, мин әле дә алны-ялны белми белем баскычына үрмәлим, максатым мине үзенә чакыра.

Син нәни күңелемә белем орлыкларын салдың. Тәрбияләдең, бар назыңны, йөрәк җылыңны, күңел тереклеген нигез ташы итеп миңа терәк иттең. Кояш нурлары тереклеккә ничек кирәк булса, эчәр суга кеше ничек мохтаҗ, күкрәк тутырып сулар ирек һавасы читлектәге ярсу йөрәкле нәни сандугачкани дәрәҗәдә мөһим икән, син миңа аннан мең мәртәбә артык кадерлесен.

## Дөнья үзебезнеке

# Мөселман киносында - безнең студентлар



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

5-11 сентябрь көннәрендә Казаныбызда VIII Халыкара мөселман киносы фестивале үтә. Татарстанда ул 2005 елдан бирле уздырыла. Чараның төп максаты: Россия һәм мөселман илләре арасында мәдәният, сәнгать өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу; мөселман кинематографларына тагын да зуррак мөмкинлекләр ачу һәм, әлбәттә, мөселман дөньясы, ислам дине турында башка халыкларда дөрес караш тудыру.

Фестиваль дәвамында 28 ил фильмнары каралачак. Конкурсантлар арасында чит төбәкләрдән килүчеләр бихисап. Мәсәлән, Һиндстан, Төркия, Иран, Казахстан, Кыргызстан, Польша, Бахрейн, Венесуэла, Занзибар, Гарәп әмирлекләре илләреннән, Россиянең башка төбәкләреннән кунаклар килде. Шул уңайдан 4 сентябрь көнне «Родина» күңел ачу үзәгендә тәрҗемәче-волонтерларны сайладылар. Араларында Ислам университеты белән беррәттән Казан федераль университеты студентлары да бар иде. Алар өчен бу менә дигән тәҗрибә, чөнки студентлар танылган режиссер-сценарист, журналистларның чыгышларын тәрҗемә итәчәк. Уңышлы эшләгән һәр студентка оештыручылар тарафыннан рәхмәт хатлары тапшырылыр дип көтелә. VIII Халыкара мөселман киносы фестиваленең конкурс программасына кертелгән фильмнарын «Родина» кинотеатрында карарга мөмкин. Калган фильмнар тамашачыларга «Мир», «Киномакс» һәм «Киномечта» кинотеатрларында күрсәтеләчәк. Укудан бушаган арада кинога йөрергә яратучы студентлар өчен дә менә дигән мөмкинлек бу. Бердән, бушка, икенчедән, югары белем алучы укучыларга башка илләр мәдәнияте һәм сәнгате белән таныш булып тору зыянлы булмас!

# Яңа уку елына... энтузиазм белән!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
журналистика һәм социология факультеты студенты

Ниһаять, беренче уку атнасы башланып китте. Бишенче курска җиткәч, шундый нәтиҗә ясыйм: һәрбер курс өчен уку елының беренче көннәре үзенәлекле: беренчеләр өчен – яңа танышулар, яңа тормыш башлануы; икенче, өченче курслар яңа уку елына төркемдәшләрен сагынып, бу юлы нинди яңа фәннәр керүе белән кызыксынып керә, дүртләр, бишләр, гадәттә, «Укуның соңгы еллары! Вакыт бигрәк тиз үтә икән», – дип гаҗәпләнә...



Шулай да күпләр сентябрь башлану белән, «Уф, тагын уку, парлар» – дип уфтана башлый. Бу хәл сиңа танышмы? Алайса, синең карашны бераз үзгәртергә тырышып карыйм.

Уку елының күңелле очрашулардан башлануы турында әйтеп торасы да юк. Ләкин төркемдәшләреңнән тыш, Казанга хәзер башка дусларың да агыла – димәк, ял көннәрендә бергәләп күңел ачулар, салкын яңгырлы кичләрдә җыелышып, кызыклы әңгәмә корулар сезоны кабат ачык!

Моннан тыш, уку елы ничектер үзеннән-үзе безгә җитдилек, эшлеклелек рухын өсти. Ә бу – үзеңне укуда күрсәтергә мөмкинлек, шәхес буларак үсү, яңа белемне продуктив үзләштерү дигән сүз.

Алай гына да түгел, парлар башлану студентка үзенең буш вакытын, көндәлек режимын төгәлрәк планлаштырырга, вакытны файдалырак, нәтиҗәлерәк уздырырга этәргеч бирә. Димәк, җәйге нон-стоп рәвешендәге ял, күңел ачу режимыннан читләшеп, кирәкле һәм файдалы эшләрнең төгәл вакытын билгеләргә мөмкин. Әйтик, иртән – уку, төштән соң – нинди дә булса спорт секциясе, фитнес, бию һ.б. Син бит инде күптәннән җыенасың, шулаймы? Сентябрь – яңа эшләр өчен менә дигән вакыт! Вакыт дигәннән, парның төгәл тәртибе эшләгән студентларга эш вакытларын чамаларга, уңайлы шартлар тудырырга да ярдәм итә.

Иң мөһиме, уку елы студентларны үзара якынайта, таныштыра һәм... кавыштыра. Димәк, ялгызларның насыйп ярларын табу мөмкинлекләре дә арта.

Шуңа күрә яңа уку елына яңа көчләр, энтузиазм, илһам белән кер, дустым! Витаминнар турында онытма – көзге салкыннар һәм авитаминоз якты планнарыңны боза күрмәсен. Уңышлар телим!

## Аз-маз мәзәкләр

***

*Бер студент үлә дә тәмугка элә. Моңа ике сайлау мөмкинлеге бирәләр. Берсе гади, берсе студентлар тәмугы. Гади тәмугта һәр көн кеше башына бер кадак кагалар. Студентларныкында барсы да рәхәтләнеп йөри,күңел ача. Бу егет студентларныкын сайлый.*

*Йөри бу рәхәтләнеп, күңел ачып. Беркөнне ни күзе белән күрсен: шайтан бер чиләк кадак күтәреп килә:*

*- Йә студент, әзерлән! Сессия башланды!*

***

*Югары математика мөгаллименең яраткан эте югала. Мөгаллим табучыга имтиханда «бишле» куям дип вәгъдә итә. Шуннан бирле аның эте сессия саен берничә мәртәбә югала башлый.*

***

*ВУЗда имтихан бара. Профессор:*

*- Сезгә бер авыр сорау биримме, әллә ике җиңелнеме?*

*- Бер авырны.*

*- Алайса менә мондый сорау, җавап бир: җир шарында мамонтлар беренче мәртәбә кайда табылган?*

*- Казанның Бауман урамында.*

*- Нигә анда?*

*- Ә монысы инде икенче сорау...*

***

*- Әйдәгез, сөйләшмичә генә утырыйк әле? Монда шундый матур, рәхәт. Бу тынлыкны бер дә бозасым килми.*

*- Вәлиев,шаяртуларыгызны туктагыз! Билет алып, сорауга җавап әзерләгез.*

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ЖЧЖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.